СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
14 сентябрь, 2026 ел

КАРАР
№ 107

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 23 октябрендәге 457 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Ныклы гаилә берлекләрен бүләкләү, традицион гаилә кыйммәтләрен һәм гаиләләрнең Биектау районының социаль-мәдәни үсешенә керткән өлешләрен саклау максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2024 елның 23 октябрендәге 457 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 бүлекнең 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«-үтенечнамә биргән датага кимендә 50 ел теркәлгән никахта торучы, шул ук вакытта Биектау районы территориясендә кимендә 10 ел яшәүче, шулай ук район алдында мөһим казанышларга ия ир белән хатын.»;

2) 3 бүлекнең 3.3 пунктында «(җиде)» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3) 3 бүлекнең 3.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«- паспорт күчермәсе;

- 3 нче кушымта нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.»;

4) түбәндәге эчтәлекле 3.1 «Кимендә 50 ел теркәлгән никахта торучы ир белән хатынның кандидатураларын тәкъдим итү тәртибе» бүлеген өстәргә:

«3.1. Кимендә 50 ел теркәлгән никахта торучы ир белән хатынның кандидатураларын бүләкләү өчен тәкъдим итү тәртибе

3.1.1. Медаль белән бүләкләү өчен тәкъдимнәр ир белән хатынның эш урыны яисә үткән хезмәт эшчәнлеге урыны буенча хезмәт коллективлары, районның җирле үзидарә органнары, район территориясендә эш итүче иҗтимагый оешмалар, ветераннар советы, башка иҗтимагый советлар, ир белән хатынның туганнары (җирлек администрациясе яисә иҗтимагый оешмалар аша) тарафыннан бирелгән язма үтенечнамә нигезендә кертелә.

3.1.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктының алтынчы абзацында күрсәтелгән критерийлар нигезендә затларны медаль белән бүләкләү турындагы үтенечнамә тапшыру көненә кадәр 7 (җиде) эш көненнән дә соңга калмыйча район башлыгы исеменә җибәрелә. Үтенечнамәгә «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләүгә тәкъдим (әлеге Нигезләмәгә кушымта итеп бирелә торган расланган форма нигезендә) кушып бирелә.

3.1.3. Тәкъдимгә кушымта итеп бирелә:

- ир белән хатынның паспортлары күчермәләре;
- ир белән хатынның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;
- никахлашу турында таныклык күчермәсе;
- ир белән хатынга (коллективтан, иҗтимагый оешмадан яисә җирлек администрациясеннән) аларның район үсешенә керткән өлешләрен, иҗтимагый тормышта катнашуларын, балалар һәм оныклар тәрбияләүләрен, башка казанышларын ача торган характеристика;
- булган очракта – ир белән хатынның иҗтимагый активлыгын раслый торган бүләкләр, Рәхмәт хатлары, массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар күчермәләре.

3.1.4. Бүләкләү турындагы үтенечнамә районда билгеләнгән эш кәгазьләрен алып бару тәртибендә теркәлә. Документлар тулысынча тапшырылмаган яисә дөрес рәсмиләштерелмәгән очракта, алар билгеләнгән таләпләргә туры китерү тәкъдиме белән кире кайтарылырга тиеш.

3.1.5. Бүләкләү уртак тормыш итүнең юбилей даталарында башкарыла (50, 55, 60, 65, 70 һәм елдан артык).

3.1.6. Бүләкләүгә кандидатларның үз-үзләрен күрсәтүе рөхсәт ителми»;

5) Нигезләмәгә Кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

6) әлеге Карарга Кушымта нигезендә 1, 2 һәм 3 нче кушымталар өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2024 елның «23» октябрендәге 457 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү турындагы нигезләмәгә (2026 елның 14 сентябере № 107 редакциясендә) 1 нче кушымта

## «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләүгә тәкъдим итү

Ф.И.А. ____________________________________________________________

(рус һәм татар телләрендә күрсәтелә)

____________________________________________________________________

Туган числосы, ае, елы ______________________________________________

Туган урыны ________________________________________________________

Белеме, уку йортының исеме, тәмамлау елы _____________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

Белеме буенча белгечлеге ______________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

Биләгән вазыйфасы һәм эш урыны ________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

Галимлек дәрәҗәсе, исеме ______________________________________________
Гомуми эш стажы ____________________________________________________

Әлеге оешмада эш стажы _______________________________________________

Вазыйфада эш стажы: _________________________________________________

Бүләкләүләрнең башка төрләре дата:

- РФ _________________________________________________________________

- ТР _________________________________________________________________

- район бүләкләре ____________________________________________________

Район алдындагы казанышларын күрсәтеп, эш яисә уку урыныннан характеристика

Тармакта конкрет казанышларын күрсәтү

Вәкаләтле затның имзасы Ф.И.А.

М.У.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2024 елның «23» октябрендәге 457 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү турындагы нигезләмәгә (2026 елның 14 сентябере № 107 редакциясендә) 2 нче кушымта

Кимендә 50 ел теркәлгән никахта торучы ир белән хатынны «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү өчен тәкъдим итү лет

Ф.И.А.________________________________________________________________

(рус һәм татар телләрендә күрсәтелә)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Туган числосы, ае, елы ____________________________________________

(ире, хатыны)

Туган урыны _____________________________________________________

(ире, хатыны)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Бүләкләүләрнең башка төрләре дата:

- РФ ________________________________________________________________

- ТР ________________________________________________________________

- район бүләкләре ________________________________________________

Район алдындагы казанышларын күрсәтеп характеристика

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Вәкаләтле затның имзасы Ф.И.А.

М.У.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2024 елның «23» октябрендәге 457 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау районына 90 ел» истәлекле юбилей медале белән бүләкләү турындагы нигезләмәгә (2026 елның 14 сентябере № 107 редакциясендә) 3 нче кушымта

# ШӘХСИ БЕЛЕШМӘЛӘРНЕ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

**Мин**, ________________________________________________________________
________________________________________________________________________,
(ФИА тулысынча)
түбәндәге адрес буенча теркәлгән ____________________________________________
________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы документ: _____________, сериясе: _____номеры: ______________
бирелгән дата «_____» __________________, кем бирде _____________________________
________________________________________________________________________

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә

**ризалык бирәм** _______________________________________________________
________________________________________________________________________
(оешма исеме)

минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, ә атап әйткәндә, "Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында каралган гамәлләрне башкаруга, эш бирүчегә тапшырылган фактлар, вакыйгалар һәм тормыш шартлары турында белешмәләр белән.

Эшкәртелүләренә 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон таләпләре нигезендә ризалык биргән **минем шәхси мәгълүматларымны**, шул исәптән:

паспорт мәгълүматларын, мәгариф турындагы белешмәләрне (уку йортының исеме, тәмамлау елы, белгечлек), җенес, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем, махсус исем турындагы белешмәләр, дәүләт бүләкләре турындагы белешмәләр (шул исәптән бүләкләү датасы), бүләкләүнең башка төрләре булуы, бүләкләүләр, эшнең гомуми стажын да кертеп, элекке эш урыннары турындагы белешмәләрне

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы нигезендә мине Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары исеменнән бүләкләүләргә тәкъдим итү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләнгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары исеменнән бүләкләнгән затлар турында мәгълүмат саклау максатларында **һәркем файдалана ала дип санарга сорыйм**.

**Мин түбәндәгеләр белән риза:**

Минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарыла.

**Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аларны әлеге ризалыкта күрсәтелгән максатлар өчен һәркем файдалана алырлык итеп куллануга ризалыгым** язма рәвештә үзем ясаган махсус боерыкка кадәр сроксыз булып тора.

______________________ ______________________
(тутыру датасы) (гариза бирүче имзасы)